

Белгәнебезчә, сәләтле балалар Мордовиядә байтак. Шул исәптән, Кадошкино муниципаль районы Большие Поляны гомуми топ белем бирv мәктәбе укучылары да. Республика кvләмендә оештырылган чараларда, конкурсларда еш катнашып унышларга ирешәләр.
Бу очракта да «Объективта - донья» Республика фотоконкурсы игътибарга лаек булды. Ярышнын максаты – укучыларнын ижади сәләтен ачу һәм информацион технологияләр кvнекмәләрен практикада куллану дәрәҗәсен билгеләv. Ә конкурснын идеясе буларак фотода жәйге кvренешләрнен кызыклы моментларын фотода калдыру иде. Оештыручылары Мордовия мәгариф министрлыгы һәм ГБОДО РМ «Балаларга остәмә белем бирv Республика Үзәге».      Укучыларыбызнын мәктәптә, район кvләмендәге ярышларны жингән 20 ижади эшләрен бу конкурска жибәрдек. 5нче сыйныф укучыбыз Тумпарова Регинанын эше «Жанровое фото» номинациясендә  лаеклы 2 урын яулады. Житәкчесе – Римма Зәкәрья кызы Ляпина.
Сәләтле булгач, кvп кенә олкәдә сәләтле Регина. Ул кvпторле ярышларда я жинvче, я призерлыкны яулый. Әйтеп китик, әле генә,  Н.А.Некрасовнын 195-еллыгына багышлап vткәрелгән 3нче ачык Республика конкурсында – призер.  Бу юнәлешне Алсу Әнвәр кызы Капкаева житәкләде.
Тумпарова Регина – сәләтле йолдызчык. Ул кул эшләрен, рәсемнәрен, бисер белән эшләрен матур һәм ижади якын килеп башкара. Регина торле яктан унган бала – укуда да алдынгы, бишле билгеләренә генә укый, класстан тыш эшләре дә конкурсларда югары бәяләнә. Халык белми әйтмәс: «Сәләтле кеше, бар яктан сәләтле».

**Рима Ляпина,**
*башлангыч сыйныф укытучысы*